РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
ГЛАВА ЕГОРКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЕГОРКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Егоркино ав. КАРАР

«22» ноябрь 2020 ел № 2

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Егоркино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 10 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Садовая урамы буенча 2 нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегендә Садовая урамындагы 1-21, 2-24 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2020 елның 10 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Ленин урамы буенча 41нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегендә Ленин урамы буенча 1-57, 2-16 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2020 елның 10 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Киров урамы буенча 19нчы йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегендә Киров урамы буенча 1-31, 2-42 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2020 елның 11 ноябрендә 10сәгать 00 минутка Совет урамы буенча 10нчы йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегендә Совет урамы буенча 1-31, 10-16; Чапаев урамында 1Б-15, 2-16 йортларда, Үзәк урамы буенча 37-57, 64-78 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. 2020 елның 11 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Ирек урамы буенча 28нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авылында Ирек урамы буенча 2Б-40 йортларында, Беренче Май урамы буенча 2А-46.йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын уздыруны билгеләргә.

6. 2020 елның 11 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Егоркино авылы, Үзәк урам, 35нче йорт адресы буенча урнашкан Егоркино авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге Егоркино авылында 1-27, 2-64, Үзәк урамы; К.Маркс урамы буенча 1-45, 2-30; Ирек урамы буенча 1-9, 42-60; Беренче Май урамы буенча 1-17, 48-80.йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының алтынчы этабын уздыруны билгеләргә.

7. Халык җыенын үткәрү өчен Егоркино авылында яшәүчеләрнең исемлеген аеруга сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

8. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

9. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегенең Егоркино авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Торак пункт чикләрендә юлларны ремонтлау.

- су белән тәэмин итү челтәрләрен норматив хәлгә китерү.

« РИЗА» «КАРШЫ».

10. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

11. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Егоркино авыл җирлеге башлыгы А.И.Борисов